**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «07» июленнән № 156

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмәне расларга (Кушымта).

2. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләме һәм шул ук квалификация эшләрен башкарганда әлеге карар нигезендә билгеләнә торган хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме сакланган очракта, ул 2023 елның 30 июненә түләнә торган хезмәт хакы күләменнән кимрәк була алмый.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфаларыннан тыш) хезмәт хакы

түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 112 номерлы карары; «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә , баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфаларыннан тыш) хезмәт хакы түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 сентябрендәге 234 номерлы карары; Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә, баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфаларыннан тыш) хезмәт хакы түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 февралендәге 53 номерлы карары; Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләренә һәм белгечләренә , баш бухгалтерларына һәм бухгалтерларына (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфаларыннан тыш) хезмәт хакы түләүне оештыру һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 11 гыйнварындагы 2 номерлы карары үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2023 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа

Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «07» июленнән
156 номерлы карарына
кушымта

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында
нигезләмә

1. Әлеге «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм шартлары турында нигезләмә (алга таба - Нигезләмә)

«Казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе эшчәнлеген оештыруның аерым мәсьәләләрен регламентлаштыра һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмен, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгели.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәт хакы тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүдән, эш интенсивлыгы, акчалата бүләкләүдән, матди ярдәмнән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләүдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән тора.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 27 700 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 25 500 | |

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтеры) | | 25 500 |
| Бүлек башлыгы | 21 700 | 21 700 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 19 300 | 19 300 |
| Бухгалтер | 18 000 | 18 000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып структурада кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны 5 берәмлектән дә ким булмаска тиеш».

3. Үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчесенә һәм белгечләренә түбәндәгеләр билгеләнә:

1) тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка түбәндәге күләмнәрдә айлык өстәмә:

| Эш стажы булганда | Айлык өстәмә, процентлар |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә эш интенсивлыгы өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү;

3) еллык түләүле отпуск биргәндә вазыйфаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Хезмәткәр эштән киткән очракта, агымдагы елда бер тапкыр бирелә торган түләү хисапланмый һәм түләнми.

Беренче елда еллык түләүле отпуск бирелгәндә хезмәткәргә бер тапкыр түләнә торган түләү календарь елда эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә башкарыла. Эшләнгән вакыт эшкә кергән көннән агымдагы елның 31 декабренә кадәр исәпләнә.

4) вазыйфаи окладның ике проценты күләмендә айлык акчалата бүләкләү;

5) вазыйфаи окладның бер проценты күләмендә премия, хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә премия (премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

6) хезмәт өчен түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм, аны түләү тәртибе яллаучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан билгеләнә.

4. «Казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МКУ җитәкчеләренең һәм белгечләренең еллык хезмәт хакы фонды түбәндәге формула буенча исәпләнә

$$FOT = \sum_{1}^{n}\left((0_d + 0.3 * 0_d) * k\right) * (1 + t) + \sum_{1}^{n} P * (1 + t);$$

биредә:

- FOT җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык хезмәт хакы фонды;

$O_d$- җитәкчегә һәм белгечкә бер айга вазыйфаи окладлар түләү өчен акча суммасы;

0,3 * $O_d$– тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләү, эш киеренкелеге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә, акчалата бүләкләү, еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү, матди ярдәмне күрсәтү өчен түләү суммасы;

P – җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең еллык премия фонды (әлеге *Нигезләмәнең 3 пунктындагы 5 пунктчасында билгеләнгән шартлардан чыгып билгеләнә);*

- җитәкчеләрнең һәм белгечләрнең штат саны;

k - 12 ай;

t - хезмәт өчен түләү буенча исәпләмәләр.